ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 февраль 2025ел № 1272

Башкарма комитетның 2019 елның 25 сентябрендәге 4863 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 25 сентябрендәге 4863 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2020 елның 3 августындагы 3706 номерлы, 2023 елның 18 маендагы 4068 номерлы, 2024 елның 25 октябрендәге 7079 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия турында акт яки гаебен кичерү акты яки бюджет керемнәре администраторының бюджетка түләүләр буенча бурычны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалтуга нигез булган суд акты кулланылганда;»;

2) 5 пунктта:

- 3 пунктчада «хисапларыннан өземтә» сүзләрен «белешмә» сүзләренә алмаштырырга;

- 4 пунктчада «шәһәр бюджетына түләүләр буенча» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә билгеләнгән бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча

дебитор бурычларын түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен тормышка ашыру регламентында каралган;»;

- 5 пунктчаның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия турында акт яки гаебен кичерү акты яки бюджет керемнәре администраторының бюджетка түләүләр буенча бурычны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалтуга нигез булган суд акты;»;

- 5 пунктчага түбәндәге эчтәлектәге унберенче абзац өстәргә:

«- Бердәм федераль банкротлык турында белешмәләр реестрыннан гражданның судтан тыш банкротлык процедурасы тәмамлану турында мәгълүматларны үз эченә алган документ.»;

- 7, 8 пунктчалар үз көчен югалткан дип танырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов